**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав., 423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ___________ 08.07.2024 № ПР-126 КАРАР №____

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарын урып-җыю чорына әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыруга кызыксындыру, үсемлекчелек тармагын үстерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарын урып-җыю сезонына әзерләү турындагы нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең көзге урып-җыю сезонына әзерлеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 21 июлендәге ПР-113 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырылган көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов

ТР Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына __________ 2024 ел,№ПР___
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарын урып-җыю чорына әзерләү турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре комбайннарын урып-җыю сезонына әзерләү турындагы нигезләмә урып-җыю кампаниясендә катнашкан хезмәткәрләрнең һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыру, хезмәт нәтиҗәлелеген арттыру максатларында эшләнгән.

Комбайнчыларның экипажларын бүләкләү Актаныш муниципаль районы бюджеты хисабына башкарыла.

2. Комбайннарны карау һәм комбайнчылар экипажларын бүләкләү тәртибе.

Карау ел саен район зоналары буенча уздырыла:

1. Беренче зона - Богады-Сәфәр-Байсар-Чишмә юллары киселеше;
2. Икенче зона - Байсар МТП;
3. Өченче зона-Сәфәр-Яхшый юлы киселешендәге кыр;
4. Дүртенче зона - Әтәс авылы кыры (МТП);
5. Бишенче зона-Такталачык авылы кыры (МТП);
6. Алтынчы зона Уразай авылы кыры;
7. Җиденче зона - Аэропорт кыры.

Комбайннарның көзге урып-җыю сезонына әзерлеген карау түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

- комбайнны 2024 елгы уңышны җыю сезонына әзерләү;
- комбайнны эшкә әзерләү һәм эш процессы;
- эш барышында куркынычсызлык техникасын белү;
- һөнәри сыйфатлар.

3. Җиңүчеләрне бүләкләү ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган комиссия карары нигезендә башкарыла, комиссия составына Башкарма комитет җитәкчесе Р.А.Ильясов, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Н.Ә.Сәлимгәрәев, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең ФЭБ башлыгы Д.З.Мөхәммәтдинов, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү бүлеге башлыгы Р.Р.Мөхәмәдиев, Россия авыл хуҗалыгы үзәге ФДУ Актаныш филиалы башлыгы А.А.Сәрвәров, Дәүләт техник күзәтчелегенең Актаныш филиалы башлыгы И.М.Хәкимов керә.

3.1 Җиңүчеләрне бүләкләү комиссия карары буенча бер экипажга 2000 сум күләмендә башкарыла.

4. Карауда 72 экипаж катнаша.

ТР Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

карарына __________ 2024 ел,№ПР___
2 нче кушымта

Комиссия составы

Комиссия рәисе:
Башкарма комитет җитәкчесе Р.А.Ильясов.

Комиссия әгъзалары:
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Н.Ә.Сәлимгәрәев;
ФЭБ башлыгы Д.З.Мөхәммәтдинов;
Җитештерү бүлеге башлыгы Р.Р. Мөхәмәдиев;
Россия авыл хуҗалыгы үзәге ФДУ Актаныш филиалы башлыгы А.А.Сәрвәров;
Дәүләт техник күзәтчелегенең Актаныш филиалы башлыгы И.М.Хәкимов.